СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

26.04.2021　　　　с. Верхний Услон　　　　№ 10-106

Муниципаль хезмәткәрнең һәм Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләүче затның персональ мәгълүматлары белән эш оештыру һәм аларның шәхси эшләрен алып бару турындагы Нигезләмәләрне раслау хакында

"Персональ мәгълүматлар турында" 2006нчы елның 27нче июлендәге № 152-ФЗ Федераль закон нигезендә, 2006нчы елның 27нче июлендәге «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1 . Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында Нигезләмәне расларга (1нче кушымта) .

2. Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль вазыйфаны биләүче затның шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәне расларга (2нче кушымта).

3. Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында Югары Ослан муниципаль районы Советының 2009нчы елның 21нче июлендәге 39-401нче карары белән расланган Нигезләмә үз көчен югалткан дип санарга.

4. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә:

- муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның шәхси мәгълүматларын федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә аларны хокуксыз куллanудан яки югалтудан саклауны тәэмин итәргә;

- муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге персональ мәгълүматларны саклау режимын бозган өчен җаваплылык тотучы затларны билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы　　　　М. Г. Зыятдинов